# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында**
**Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2; Ватаным Татарстан, 2010, 31 март, 2 апрель) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.3 – 5.6 статьялар өстәргә:

"5.3 статья. **Билгеләнгән тәртиптә пассажирлар йөртүнең заказчысы белән төзелгән шартнамәдән башка маршрут транспорт чаралары белән пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру**

Даими маршрутлар буенча пассажирлар һәм багаж йөртү буенча хезмәтләр күрсәтүгә пассажирлар йөртүнең заказчысы белән төзелгән шартнамәдән башка Татарстан Республикасының маршрут челтәренә яисә муниципаль маршрут челтәренә кертелгән даими муниципальара, муниципаль маршрутлар буенча маршрут транспорт чаралары белән пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырган өчен –

транспорт чарасы белән идарә итүче гражданнарга – ике мең сумнан алып өч мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – егерме мең сумнан алып утыз мең сумга кадәр; юридик затларга илле мең сумнан алып алтмыш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен –

транспорт чарасы белән идарә итүче гражданнарга – дүрт мең сумнан алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – кырык мең сумнан алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз мең сумнан алып йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

5.4 статья. **Пассажирлар йөртүнең заказчысы тарафыннан расланган хәрәкәт расписаниесен бозып, маршрут транспорт чараларында даими маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру, шулай ук пассажир йөртүченең, вәкаләтле органнарга хәбәр итмичә, маршрут паспорты белән расланган маршрутта хәрәкәт расписаниесен үзгәртүе**

Даими муниципальара яисә муниципаль маршрутта билгеләнгән рейсларны пассажир йөртүче юкка чыгарган яисә хәрәкәт расписаниесен үзгәрткән, шулай ук пассажир йөртүче, вәкаләтле органнарга хәбәр итмичә, маршрут паспорты белән расланган маршрутта хәрәкәт расписаниесен үзгәрткән өчен –

вазыйфаи затларга – биш мең сумнан алып ун мең сумга кадәр; юридик затларга унбиш мең сумнан алып егерме мең сумга кадәр административ штраф салына.

Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен –

вазыйфаи затларга – унбиш мең сумнан алып егерме мең сумга кадәр; юридик затларга егерме биш мең сумнан алып утыз мең сумга кадәр административ штраф салына.

5.5 статья. **Пассажирларны автовокзаллардан (пассажир автостанцияләреннән) алып китүнең билгеләнгән тәртибен бозып, шәһәрара һәм шәһәр яны юлларының даими маршрутлары буенча маршрут транспорт чараларында муниципальара пассажирлар йөртүне яисә шәһәр яны юлларының даими маршрутлары буенча маршрут транспорт чараларында муниципаль йөртүләрне гамәлгә ашыру**

Пассажирларны автовокзаллардан (пассажир автостанцияләреннән) алып китүнең пассажирлар йөртүнең заказчысы тарафыннан билгеләнгән тәртибен бозып, шәһәрара һәм шәһәр яны юлларының даими маршрутлары буенча маршрут транспорт чараларында муниципальара пассажирлар йөртүне яисә шәһәр яны юлларының даими маршрутлары буенча маршрут транспорт чараларында муниципаль йөртүләрне гамәлгә ашырган өчен –

транспорт чарасы белән идарә итүче гражданнарга – ике мең сумнан алып өч мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – егерме мең сумнан алып утыз мең сумга кадәр; юридик затларга илле мең сумнан алып җитмеш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен –

транспорт чарасы белән идарә итүче гражданнарга – дүрт мең сумнан алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – кырык мең сумнан алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз мең сумнан алып йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

5.6 статья. **Пассажирны йөртүдән баш тарту**

Пассажирлар йөртүне коммерциячел гамәлгә ашыру очракларыннан тыш, социаль йөрү документы булган пассажирны йөртүдән баш тарткан өчен –

гражданнарга – бер мең сум; вазыйфаи затларга – өч мең сумнан алып биш мең сумга кадәр; юридик затларга унбиш мең сумнан алып егерме мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Пассажирны йөртүдән баш тарту дигәндә шушы категория гражданнарны йөртүгә транспорт чарасының тышкы яисә эчке ягында язма рәвештә тыю урнаштыру йә транспорт йөртүченең һәм (яисә) кондукторның тиешенчә рәсмиләштерелгән йөрү документларын кабул итүдән читләшүе, шулай ук йөрүдән сүз белән тыюы, физик каршылык күрсәтүе яисә социаль йөрү документы булган пассажирны йөртүгә каршы килә торган бүтән гамәлләр кылуы аңлашыла.";

2) 7.4 статьяга "3.2 – 3.6" саннарыннан соң ", 5.1, 5.2, 5.3 – 5.6 (шул муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль йөртүләргә кагылышлы)" сүзләрен өстәргә;

3) 7.6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7.6 статья. **Пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыручы орган**

Пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыручы орган әлеге Кодексның 5.3 – 5.6 статьяларында күрсәтелгән административ хокук бозулар (муниципальара пассажирлар йөртүләргә кагылышлы) турындагы эшләрне карый.

Административ хокук бозулар турындагы эшләрне әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән орган исеменнән түбәндәгеләр карарга хокуклы:

Татарстан Республикасы транспорт һәм юллар хуҗалыгы министры, аның урынбасарлары.";

4) 8.1 статьяда:

икенче өлешкә "4.4" саннарыннан соң ", 5.1, 5.2, 5.3 – 5.6 (шул муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль йөртүләргә кагылышлы)" сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче өлеш өстәргә:

"Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган очраклардан тыш, әлеге Кодексның 5.1, 5.2, 5.3 – 5.6 статьяларында каралган административ хокук бозулар (муниципальара пассажирлар йөртүгә кагылышлы) турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәләре вазыйфаи затлары төзергә хокуклы.";

сигезенче өлешне тугызынчы өлеш дип санарга һәм анда "Татарстан Республикасы дәүләт органнары" сүзләрен "органнар" сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 5 июле
№ 54-ТРЗ